ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЙНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
МАЙНА АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**09.12.2021** **№ 16**

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге башкарма комитетының резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану турындагы Нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 маддәсендәге 6 пункты нигезендә

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге башкарма комитетының резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карар, 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Майна авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Н.Гафиятуллин**

Татарстан Республикасы Алексеевск
муниципаль районы Майна авыл
җирлеге башкарма комитетының
2021 елның 9 декабрендәге
16 номерлы карарына кушымта

**Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге башкарма комитетының резерв фондыннан бюджет ассигнованиеләреннән файдалану турында Нигезләмә**

1. Алексеевск районы Майна авыл җирлеге башкарма комитетының резерв фонды күләме чираттагы финанс елына Майна авыл җирлеге бюджетын раслаганда Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге Советы карары белән билгеләнә һәм җирлек бюджетының расланган чыгымнарының 3 (өч) процентыннан арта алмый.

2. Резерв фонды акчалары җирлек, район һәм республика масштабларында социаль-икътисадый тигезлекне саклап калу өчен кирәкле көтелмәгән чыгымнарны финанслауга тотыла:

а) агымдагы финанс елында табигый бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү буенча авария-торгызу эшләрен үткәрү;

б) табигый бәла-казаларны һәм башка гадәттән тыш хәлләрне кисәтү буенча чаралар үткәрү;

в) хокук саклау органнарына һәм аларның хезмәткәрләренә, хокук тәртибен саклау буенча соңгы федераль, төбәк һәм район программаларын гамәлгә ашырганда, урыннарда да, район һәм республикадан читтә дә финанс ярдәме күрсәтү;

е) халык иҗатын, фольклорын үстерү һәм талантларга ярдәм итү өчен финанс ярдәме күрсәтү;

ж) табигый бәла-казалар, янгыннар һәм башка гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән гражданнарга финанс ярдәме күрсәтү;

з) социаль әһәмиятле, мәдәни объектлар, инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар өчен торак төзелешен, капиталь ремонтын өлешчә финанслау;

и) җәмәгать оешмаларына өлешчә финанс ярдәме (инвалидлар - әфганчылар һәм башкалар);

й) гомумдәүләт, республика, район программаларын һәм карарларын ел дәвамында расланган көтелмәгән финанслау.

3. Резерв фонды акчаларын тоту Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге башкарма комитеты күрсәтмәләре һәм карарлары нигезендә башкарыла.

4. Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге башкарма комитетының резерв фонды акчаларыннан файдалану турындагы хисап бюджет үтәлеше турындагы квартал саен бирелә торган хисапка кушымта итеп бирелә.